2 нче сыйныф уку.

Үзем һәм гаиләм турында. Туганлык мөнәсәбәтләре

(О себе и своей семье. Родственные отношения)

Минем исемем - Маша. Мин Казан шәһәрендә яшим. Мин 2 нче сыйныфта укыйм. Мина 8 яшь. Мин тарих, музыка, спорт белән кызыксынам һәм русча, инглизчә, татарча өйрәнәм. Миңа жиңел атлетика ошый. Мин һәр көнне тренировкага йөрим. Гаиләбездә 6 кеше бар. Бу - әнием, әтием, әбием, бабам, апам (абыем, сеңлем, энем) һәм мин. Әниемнең исеме - Элина. әтиемнең исеме - Артур. Әбием - Антонина Сергеевна, а бабам – Николай Иванович. Апамның исеме - Настя. Гаиләбез бик тату.

Минем дусларым да куп. Дусларым белән без музейларга, кафларга йөрибез. Мин аларны яратам.

3 нче сыйныф уку.

Мин бәйрәмнәрне бик яратам. Без Яңа ел, 23 нче февраль, 8 нче Март, 9 нчы Май, 1 нче сентябрь - Белем бәйрәмен, туган көннәрне үткәрәбез. Зур бәйрәмнәрнең берсе - 9 нчы Май - Жиңү көне. Бу көнне паркларда Бөек Җиңүгә багышланган бәйрәм парадлары уздырыла. Халык, бердәм булып, «Үлемсез полк» акциясендә катнаша. Орден-медальләрен таккан ветераннар - бу бәйрәмдә иң кадерле кунаклар. Кешеләр аларны бәйрәм белән котлыйлар, бугенге тыныч, матур тормыш өчен рәхмәт әйтәләр, чәчәкләр, бүләкләр бирәләр. Һәйкәлләргә, мемориалларга чәчәкләр куела. Мәңгелек ут янында, паркларда ветераннарга, тыл геройларына багышланган концертлар була. Бәйрәм салют белән тәмамлана.

23 нче февраль - Ватанны саклаучылар көне. Бу көнне солдатлар һәм офицерларны гына тугел, барлык ир-егетләрне дә бәйрәм белән котлыйлар. 8 нче Март та - бик матур һәм куңелле бәйрәм. Бу көнне хатын-кызларга чәчәкләр һәм буләкләр бирү матур традициягә әйләнгән. Мин әниемне бәйрәм белән котлыйм. Аңа сәламатлек, бәхет телим.

Гомумән, кешеләр бәйрәмнәрне котеп алалар һәм туганнары, дуслары белән куңелле, матур уздыралар.

Гаиләбездә да бәйрәмнәр үткәрү - матур традиция. Бәйрәмнәрдә туганнарыбыз белән җыелабыз. Бәйрәм табыны әзерлибез. Бәлеш, гөбәдия пешерәбез. Куңелле була.

С у з л е к:

| | |
|---|---|
| бәйрәм табыны - праздничный стол | бердәм булып - едино, дружно |
| телефоннан - по телефону | Үлемсез полк - Бессмертный полк |

**Тема буенча сораулар:**

- *Син нинди байрәмнәрне беласен?*

- *Синен ин яраткан бәйрәмен нинди?*

4 нче сыйныф өчен уку.

Һәркем сәламәт булырга тели. Сәламәт булу өчен яхшы һәм дөрес тукланырга кирәк. Һшркем белә: ризыкта витаминнар булырга тиеш. Яшелчә һәм җиләк-җимешләрне күп һәм даими ашарга кирәк.

Иртән физик күнегүләр ясау, тешне чистарту да мөһим. Саф һавада йөрү, йөгерү дә файдалы. Җәен су коенырга, урманга барырга кирәк. Кышын чаңгыда, тимераякта шуу файдалы.

Һәркем үз сәламәтлкген сакларга тиеш. Сәламәт яшәү өчен, начар гадәтләр булмаска тиеш. Күп борчылырга ярамый. Начар кешеләр белән аралашмаска кирәк. Сәламәт кешеләр бәхетле була. “Сәламәтлек – зур байлык” дигән мәкаль бар.

5 нче сыйныф өчен уку.

Татарстан Республикасы Идел буенда урнашкан. Аның мәйданы – 68 мең квадрат километр. Халкы – 3 миллион 780 мең кеше. Татарстанда 100 дән артык милләт вәкиле яши. Татарстан Республикасы составында 20 шәһәр, 43 район, 3 меңгә якын авыл исәпләнә. Иң зур шәһәрләр – Казан, Яр Чаллы, Түбән Кама, Әлмәт, Яшел Үзән, Бөгелмә. Татарстанда вертолётлар, “КамАЗ” машиналары, суыткычлар һәм башка кирәкле товарлар җитештерелә.

Татарстанда танылган театрлар, музейлар, югары уку йортлары, китапханәләр эшли. Биредә ел саен Рудольф Нуриев исемендәге халыкара балет фестивале, “Алтын мөнбәр” халыкара мөселман фильмнары фестивале үткәрелә, халыкара спорт ярышлары да еш уздырыла.

Бүгенге көндә Татарстан – икътисади, фәнни һәм мәдәни үзәк.

6 нчы сыйныф уку.

Казан университеты.

Казан университеты – Россиядәге иң борынгы университетларның берсе. Ул 1804 нче елның 17 нче ноябрендә ачылган. Беренче көннәрдән биредә зур галимнәр эшләгән. Моңа кадәр мәдрәсәләрдә белем алган татарлар, яратып, аны “университет исемле олы мәдрәсә” дип йөрткән.

Карл Фукс, Илья Березин, Николай Лобачевский кебек зур галимнәр белән янәшә татар әдипләре дә университет үсешенә өлеш керткән. Каюм Насыйри һәм Шиһабетдин Мәрҗаниләр Казан университеты белән бик тыгыз элемтәдә торган.

Университетның үз типографиясе була. Ул 1809 нчы елда ачыла. Биредә бик күп китаплар басыла. Уку йортының китапханәсе дә бик бай. Ул 1953 нче елдан Николай Лобачесвкий исемен йөртә.

Казан университетында танылган татар язучылары, шагыйрьләре дә белем алган: Нурихан Фәттах, Гариф Ахунов, Аяз Гыйләҗев, Равил Фәйзуллин, Рәдиф Гаташ һәм бик күп башка танылган кешеләр.

2009 нчы елда Казан университеты нигезендә Казан (Идел буе) федераль университеты оештырыла.

7 нче сыйныф уку.

Танылган татар композиторы Фәрит Яруллин

Танылган татар композиторы Фәрит Яруллин Казанда Суконный бистәсенда туа. Аны әтисе Заһидулла Яруллин - музыкант, бик күп җыр һәм инструменталь пьесалар, танылган «Тукай маршы» авторы.

Башлангыч музыкаль белемне Фәрит Яруллин әтисеннән ала. Аннары ул Казан сәнгать техникумына укырга керә. Башта виолончель буенча, аннан соң фортепьяно классында белем ала. Техникумда укыганда, үзешчән хор түгәрәкләре оештырып, аларга җитәкчелек итә, яңа ачылган яшьләр театрында, сүзсез кинофильмнарда музыка башкара.

1933 нче елда Фәрит Яруллин Мәскәу консерваториясенең татар опера студиясенә укырга керә. Монда укыганда, ул жырлар, романслар, инструменталь миниатюралар иҗат итә. 1937-1938 нче елларда ул Габдулла Тукайның әкият-поэмасы буенча «Шүрәле» балетын яза башлый. Ләкин балет сәхнәдә куелмыйча кала - сугыш башлана. Фәрит Яруллинны да сугышка җибәрәләр. 1942 нче елда ул сугыш кырында һәлак була. Бик озак хәбәрсез югалганнар исемлегендә йөри. Композиторның кабере кырык елдан соң гына табыла.

Фәрит Яруллин - беренче татар милли балетын тудырган музыкант. Аның «Шүрәле» балеты 1945 нче елдан алып Казанда, Мәскәүдә генә түгел, төрле республика башкалалары театрларында да, Болгария, Румыния, Германия кебек илләрнең сәхнәләрендә дә уйнала. Балетны Татарстан тамашачылары да, чит ил кунаклары да яратып карыйлар.

Танылган татар композиторы Фәрит Яруллинның иҗаты һәм тормышы турында язучы Рашат Низамиев «Ут һәм жыр» роман-хроникасын язды.

С у з л е к:

танылган - знаменитый

үзешчән - самодеятельный

җитәкчелек итү - руководить

сынап карый – *здесь*: проверяет себя

куелмыйча кала -- *здесь*: остается не поставленным

хәбәрсез югалганнар– без вести пропавшие

һәлак була - погибает кабер - могила

***Тема буенча сораулар:***

- *Фәрит Яруллин кем ул?*
- *Син балет белән кызыксынасыңмы?*

8 нче сыйныф уку.

Татар галиме Каюм Насыйри

Каюм Насыйри – галим, мәгърифәтче, тарихчы, язучы, дәреслекләр һәм сүзлекләр авторы.

Каюм Насыйри 1825 нче елда туган. Ул башлангыч белемне әти-әнисеннән ала, аннан соң Казанда мәдрәсәдә укый. Анда гарәп, фарсы телләрен өйрәнә. 1855 нче елдан К.Насыйри Духовный учиилищеда ( соңрак Духовная семинария) татар теле укыта башлый. 1871 нче елдан ул татар балаларына рус теле укыта.

Каюм Насыйри – дәреслекләр авторы. Рус балаларын татарчага, татар балаларын русчага өйрәтү өчен иң беренче дәреслекләрне Каюм Насыйри язган. Тагын ул математика, география, ботаника буенча дәреслекләр төзеп чыгарган.

Татар теленең беренче фәнни грамматикасы, аңлатмалы сүзлеге, беренче русча-татарча, татарча-русча сүзлекләр, математика, география, табигать фәннәре буенча татарча терминнар сүзлеге – Каюм Насыйриның зур хезмәтләре. Ул рус, татар грамматикаларында булган аермаларны өйрәнә, аларны укучыларына аңлата. К.Насыйриның бу яңалыгы – хәзерге көндә дә уңышлы методларның берсе.

Каюм Насыйриның әдәби эшчәнлеге дә күп кырлы. Ул халкыбызның гореф-гадәтләрен, этнографиясен, тарихын өйрәнә, аларны туплап бастыра, татар телендә беренче өстәл календарен чыгара. Күп санлы тәрҗемәләре, үз язмалары, фольклор материаллары – безгә галим калдырган зур мирас.

Бөек галимне халкыбыз бүген дә олылый. Башкалабыз Казанда Каюм Насыйри музее бар. Мәгариф өлкәсендәге уңышлар өчен Каюм Насыйри исемендәге премия булдырылган.

С ү з л е к:

мәгърифәте – просветитель

галим – ученый

тагын – здесь: ещё

әдәби эшчәнлек – литературная деятельность

гореф-гадәтләр – традиции

күпкырлы – многогранный мирас - наследие

Тема буенча сораулар:

- Каюм Насыйри кем ул?
- Каюм Насыйри кайсы фәннәр буенча дәреслекләр язган?

9 нчы сыйныф уку.

Мәскәү (Москва)

1.

Мәскәү - Россиянең башкаласы. Ул - зур шәһәрләрнең берсе. Ул Мәскәү елгасы буенда урнашкан. Башкалабыз Мәскәү - бик борынгы шәһәр. Ул Юнеско дөнья мирасына кергән. Анда Кремль, Кызыл мәйдан, Арбат урамы бар. Кремльдә Президент резиденциясе, Спас манарасы урнашкан.

Мәскәүдә борынгы архитектура истәлекләре, музейлар, театрлар, концерт заллары, матур йортлар бик куп. Зур һәм Кече театр, Корал палатасы, Тарих музее, Третьяков галереясы һәм башка бик күп биналар - шәһәрнең горурлыгы.

Мәскәүдә дөньяга танылган уку йортлары да күп. Ел саен баш-калабызга илебезнең төрле төбәкләреннән күп студентлар укырга килә.

Мәскәүдә заводлар һәм фабрикалар, төзелеш, сәүдә, спорт узәкләре дә күп. Башкалабызга 6 аэропорт, 9 тимер юл вокзалы, 3 елга порты хезмәт курсәтә.

Мәскәү дөньядагы иң матур, иң бай тарихлы шәнәр.

2. Мәскәү -- безнең туган илебезнең - Россиянең башкаласы. Ул - Европадагы иң зур шәһәрләрнең берсе. Ул Мәскәү елгасы буенда урнашкан. Мәйданы -- 2511 кв. км., халык саны - 12 миллионнан артык. Башкалабыз Мәскәү -- бик борынгы шәһәр. Тарихи истәлекләр буенча Мәскәүгә 1147 нче елда князь Юрий Долгорукий нигез салган.

Мәскәү шәһәре 12 административ округка бүленгән. Шәһәрнең административ үзәге Үзәк административ округта урнашкан. ЮНЕСКО дөнья мирасына кергән Кремль, Кызыл мәйдан, Арбат урамы – шәһәрнең үзәгендә. Кремльдә Президент резиденциясе, Спас манарасы урнашкан. Кызыл мәйдандагы бөтен дөньяга билгеле Василий Блаженный соборы, Минин һәм Пожарскийга һәйкәл, Мавзолей, җәяүле Арбат урамы - төрле илләрдән килгән туристлар өчен иң матур һәм истәлекле урыннар.

Мәскәүдә борынгы архитектура истәлекләре, музейлар, театрлар, концерт заллары, заманча кунакханәләр, зур сәүдә узәкләре, матур йортлар бик куп. Зур һәм Кече театр, Корал палатасы, Тарих музее, Третьяков галереясы һәм башка бик күп урыннар - шәһәрнең горурлыгы.

Мәскәүдә бөтен дөньяга танылган уку йортлары бик күп. Ел саен башкалабызга төрле төбәкләрдән, чит илләрдән бик күп абитуриентлар укырга килә.

Мәскәү - зур промышленность үзәге. Монда машина төзелеше, төсле һәм кара металлургия, химия, полиграфия промышленносте зур үсешкә ирешкән.

Башкалабызда 6 аэропорт, 9 тимер юл вокзалы, 3 елга порты бар. 1937 нче елдан метрополитен эшли. Гомумән, Мәскәү - дөньядагы иң матур, иң бай тарихлы шәһәрләрнең берсе.

С у з л е к:

| | |
|---|---|
| борынгы - старинный, древний | нигез салган - основал |
| дөнья мирасы - мировое наследие | җәяүле - здесь: пешеходная |
| истәлекле -- памятный | горурлыгы -- гордость |

10 нчы класс уку.

Заманның глобаль проблемалары

(Глобальные проблемы современности)

Глобаль проблемалар - бөтен кешелек дөньясына куркыныч тудырган проблемалар. Аларны бөтендөнья җәмәгатьчелеге белән бергәләп кенә хәл итәргә мөмкин. Бу проблемалар хәл ителмәсә, бөтен планетаның киләчәге куркыныч астында булачак. Менә ул дөньяны катастрофага китерә торган проблемалар:

- экологик проблема - кешеләрнең табигатькә сакчыл карамавы нәтиҗәсендә әйләнә-тирә мохитнең, урман-суларыбызның пычрануы, табигый байлыкларның, файдалы казылмаларның бетүе;

- атом-төш коралы проблемасы - иң куркыныч глобаль проблема - күпләп корал ясау, атом-төш коралын сынау нәтиҗәсендә җир шарының радиоактив пычрануы; атом-төш терроризмы куркынычы;

-- демографик проблема - үсеп килүче һәм алга киткән илләрдә халык санының пропорциональ усмәве;

- кризис шартларында Җирдәге халыкка энергия, чиста су, чиста һава, азык-төлекнең җитмәве;

- сәламәтлек саклау проблемасы - наркомания, алкоголизм, тәмәке тарту, хәерчелек, онкология, СПИД таралу проблемалары;

- кешенең рухи кризисы - рухи кыйммәтләр бетү;

- фәнни-техник революциянең тискәре йогытнтысы: табигатьнең юкка чыгып баруы, яңа төр корал уйлап табулар, компьютер революциясенең кешеләргә тискәре йогынтысы (сукыраю; психик тайпылышлар, аралашу бетү, стресслар, нерв һәм йөрәк-кан системасы авыруларының артуы).

Соңгылары яшүсмерләребез тормышына бәйле булуы белән аеруча куркыныч.

Глобаль проблемаларны бөтен кешелек дөньясы, дәүләт җитәкчеләре узара килешеп, бергәләп хәл итәргә тиеш, дидек. Тик без бу проблемаларны хәл итугә һәркайсыбыз купмедер өлеш кертә алабыз. Үзебез яшәгән җирдәге

кечкенә проблемаларны чишә алабыз. Җир йөзендәге һәркем шулай җаваплы караса, глобаль проблемалар да чишелер иде.

11 нче класс уку.

Лондон

Лондон - Бөекбританиянең башкаласы. Ул - дөньядагы иң зур шәһәр. Лондон - Темза елгасы буенда урнашкан. Ул - бик матур һәм борынгы шәһәр.

Лондон берничә өлешкә бүленгән. Сити - иске шәһәр, Лондонның финанс һәм коммерция үзәге. Вестминстер - башкаланың административ узәге. Зур кибетләр, кунакханәләр, музейлар, театрлар, концерт заллары шәһәрнең Уэст-Энд өлешендә урнашкан. Ист-Энд - зур промышленность үзәге. Монда заводлар, фабрикалар урнашкан.

Лондонның иң истәлекле урыннарының, берсе - Королева резиденциясе. Лондонның иң зур музее - Британ музее. Ул – инглизләрнең горурлыгы. Бу музей дөньядагы иң зур китапханәсе белән танылган.

2.

Лондон - Бөекбританиянең башкаласы, икътисади, сәяси, модели үзәге. Ул - дөньядагы иң зур шәһәрләрнең берсе. Аның мәйданы -1865 кв.км. Халкы - 11 миллионан артык. Лондон - Темза елгасы буенда урнашкан бик матур һәм борынгы шәһәр. Ана 2000 ел элек нигез салынган.

Лондон берничә өлешкә бүленгән: Сити, Уэст-Энд, Ист-Энд һәм Вестминстер. Сити - иске шәһәр, Лондонның финанс нам коммерция үзәге. Вестминстер башкаланың административ үзәге. Монда ике манаралы, зур сәгатьле бик матур парламент бинасы урнашкан. Зур кибетләр, кунакханәләр, музейлар, театрлар, концерт заллары шәһәрнең Уэст-Энд өлешендә урнашкан. Матур йортлар, парклар, скверлар, киң урамнар күп монда. Ист-Энд - зур промышленность үзәге: заводлар, фабрикалар бу районда урнашкан.

Лондонның иң истәлекле урыннарының берсе - Королева рези-денциясе - Букингем сарае. Трафальгар мәйданы, Лондонның иң зур музее - Британ музее - болар инглизләрнец горурлыгы. Бу музей дөньядагы иң зур китапханәсе белән танылган. Лондонда бөтен дөньяга билгеле урамнар да күп: Оксфорд-стрит, Даунинг-стрит һәм башкалар.

Лондонда булырга туры килсә, карап сокланырлык урыннар бик күп.